Чыганак: Галимуллин Ф. Г. Эзләнү вакыты / Ф. Г. Галимуллин. - Казан: Мәгариф, 2005.- 247 б.

кояш чыгуга тиң булды. Бу кайту әдәбиятыбыз үсешенә көчле этәргеч, аның абруен нык күтәрүче факторга әйләнде.

Шуңа күрә аның 100 еллык юбилее да барлык халкыбыз өчен уртак бәйрәм булып әверелде. Шушы уңай белән без бүген Иске Кармәт авылында Хәсән ага Туфанның музей-йортын ачу тантанасына җыелдык. Без беләбез: бу олы эшне аның авылдашлары, якташлары, республикабызның төрле җаваплы оешмалары бөтен күңелләрен биреп башкарып чыктылар. Хәсән ага Туфан алтмыш елга якын үзенең туган авылына кайта алмады. Ниһаять, бары җитмешенче еллар башында гына кабат туган җиренә аяк басты. Яңа буын авылдашлары бу бөек кешене бик яратып калдылар, аңа кадер-хөрмәт күрсәттеләр.

Дөресен әйткәндә, Хәсән Туфан өчен бөтен татар халкы — авылдаш, үз кеше. Аны белмәгән, олыламаган кешене татарда табу кыен. Димәк, бу — әле Хәсән Туфан исән, ул халык күңелендә яши дигән сүз.

*2000 ел*

## НАМУСЛЫ ГОМЕР ҺӘМ ИҖАТ

Татар әдәбиятының олы әдибе Гомәр ага Бәшировның тууына 100 ел тула. Дөресен әйткәндә, аның йөзьеллыгын исән килеш каршы алуы да ихтимал иде. Һәрхәлдә, без барыбыз да шуны теләдек. Бер генә язучыбыз булса да гасыр юбилеен исән-сау каршыласа иде, аны сәхнә түренә утыртып котлый алсак иде, дип әйтүләрне бик күпләр авызыннан ишеткәнем булды. Ләкин кешегә күпме гомер бүләк итү кодрәте безнең кулда түгел шул. Гомәр ага йөз яше туларга бер елдан кимрәк вакыт калганда якты дөньядан китеп барды. Шулай да ул әле исән кебек, үзе тудырган әсәрләр һәм образлар белән бергә безнең арада яшидер сыман.

Бу өлкән әдибебез каләменең төп хасияте нидән гыйбарәт дип уйлаганда, мин үзем бер нәтиҗәгә киләм: ул чын мәгънәсендә — матурлык җырчысы. Җырчы сүзен гадәттә шагыйрьләргә карата кулланалар. Ләкин, шагыйрь әйтмешли, Тукайны яздан аерып булмаган шикелле, Г. Бәширов та халык рухыннан, халыкның дөньясыннан, халык моңыннан аерым карала алмый, аерырга теләсәң, аның иҗатының бөтенлеге кителә, табигыйлеге кими. Ак күңелле Гомәр ага каләменең очыннан ак кәгазьгә бары тик матурлык турындагы уйлар, матур хистойгылар гына түгелә. Туксан тугыз еллык гомере матурлык өчен көрәшеп узган, халкыбызга бихисап игелекле хезмәт

кылган мөхтәбәребез шуңа күрә дә милләтебезнең олы ихтирамына лаек булып яшәде.

Татар прозасының чын мәгънәсендә шигъриятен, зур сәнгатьчә көчен иң башлап Гаяз Исхакый, Фатих Әмирхан, Шәриф Камал, Галимҗан Ибраһимовлар ачты. Бу — бик көчле язучылар сафы. Без әлеге әдипләр иҗатын татар прозасының нигез ташлары буларак сыйфатладык. Әмма бу затлы нигез утызынчы елларда бик нык какшатылды. Әдәбият гөмбәзен терәп торган алтын баганалар аударылды. Ләкин затлы нигез, бәхеткә каршы, тамырларын шактый тирәнгә җибәреп өлгергән булып чыкты. Ул тамырлар әкренләп исәеп, җирнең икенче урыннарыннан тишелеп чыгып аваз салдылар. Яшь, әмма өметле үсентеләр арасында Ибраһим Гази, Фатих Хөсни, Мирсәй Әмир, Әмирхан Еники, Габдрахман Әпсәләмов һәм, әлбәттә, Гомәр Бәширов бар иде. Бу соңгысының иҗатын дөнья һәм татар әдәбиятының иң уңышлы казанышларының дәвамы, бер буыны сыйфатында гына дөрес бәяләп була. Аның эстетик карашларының җитлегүе һәм фикерләү тирәнлегенең камилләшүе процессы бары тик шул җирлектә генә ачык күренә.

Гомәр абый әле 1953 елда ук үзенең иҗат кыйбласын болай билгеләгән иде: «Кешенең бай рухи дөньясын иң катлаулы нечкәлекләре белән тасвирлау, хезмәтнең поэтик матурлыгын, яңаны иҗат итүнең куанычын көчлерәк күрсәтү». Инде бүген аның иҗатын шушы җәһәттән тәфтишләп карасак, әдипнең әлеге максатына эзлекле, һич тайпылышсыз килгәнлеген күрми мөмкин түгел. Ул каләмнең бөтен җегәрен халыкның асыл сыйфатларын типиклаштыруга салды, шул юл белән индивидуаль сәнгать образларын коюга иреште. Тормыштагыны сәнгать күренеше итеп тасвирлау югарылыгына ирешү олы талантлар кулыннан гына килә. Г. Бәширов — шушы гаять нечкә эшнең остасы. «Намус», «Туган ягым — яшел бишек», «Җидегән чишмә» дигән исемнәрдә үк никадәр аһәңлелек, югары өслүп. Илебез язмышы хәл кылынган елларда фронттагыларның да, тылдагыларның да иң олы хөкемдары үз вөҗданнары, үз намуслары иде. Әдип шушы намус дигән биниһая олы көчнең эстетик гәүдәләнешен кешеләрнең илгә, хезмәткә, бер-беренә мөнәсәбәтендә романтик буяулар белән бирә алды. Дөрес, мондый хәл тормышның үзе белән әсәрдә сурәтләнгән югары өслүп арасында бераз аерма китереп чыгарды чыгаруын, әмма бу язучының изге нияте белән аңлатыла иде. Галимебез Әбрар ага Кәримуллин раславынча, венгр телендә чыккан бер бәяләмәдә: «“Намус” романы — авыр елларда халыкның көрәше турында оптимистик поэма ул»,— диелә. Мондый бәя очраклы түгел.

Әсәрне аңлау ачкычы шактый катлаулы. Роман иҗат ителгән чорда илебез кешеләре өчен уртак булган идея-эстетик зәвыкларның (язучы шулай ук әлеге чолганыш эчендә) өстенлек итүен дә онытырга ярамый. Әмма шунысы да хак: Нәфисә, Тимери, Айсылу, Мәүлиха, Зәйнәпбану кебек кешеләр һәм аларның эшләре ул чор өчен типик иде. Биредә, Н. Г. Чернышевский сүзләренә ияреп, болай дип раслыйсы килә: «Нәфисә — гадәттән тыш оригиналь, ләкин сугыш вакытында Нәфисә булмаган кешеләр бик аз иде». Нәфисә кебекләрнең хезмәтен эстетик ләззәт алырлык итеп сурәтләп бирүе белән Г. Бәширов әдәбиятта ачыш ясады. «Алгарак омтыла төшеп, гүя, пианинода ниндидер ярсу бер көй уйнагандай, кулларын матур биетеп, барабанга көлтә бирүче» Нәфисә образы нинди сокландыргыч! Мондый хатын-кызның эчке дөньясы да ярлы була алмый, аның ярату хисләре дә гадәти генә түгелдер, бай рухлылык аны тагы да сөйкемле итә. Ул иптәшләренә дә «гөлкәйләрем» дип эндәшә. Нәфисә — бөтен барлыгы белән милли образ. Нәкъ халык җырындагыча, «эшкә батыр, төскә матур» татар хатын-кызы. Хезмәткә рухи ләззәт чыганагы, иҗатка дәрт тудыручы итеп караган, шәхси тормышларында да халкыбызның югары әхлак кануннары белән яшәүче образлар тудыруга маһирлыгы Г. Бәширов кулланма итеп алган эстетик принципларның бик әһәмиятле ягын билгеләргә ярдәм итә — ул да булса уңай идеалларны раслау. Без бу очракта В. Белинскийның «чын мәгънәсендәге талантта һәрбер зат тип була»[1] дигән сүзләренең тагын бер тапкыр раслануын күрсәтәбез.

Моның шулай икәнлеге «Туган ягым — яшел бишек» исемле автобиографик әсәрендә аеруча яңа көч белән расланды. Әсәрнең эстетик көче аның, Фатих ага Хөсни әйткәнчә, халкыбызның яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре, энциклопедиясе буларак материалны һәйбәт, чын халык теле белән, гади, әмма бик тирән мәгънәле хәл-әхвәлләрне укучыга мавыктыра алырлык итеп сурәтләп бирүендә һәм, әлбәттә, бик күп кешеләрнең коеп куйган аерым-аерым холык ияләре булуларын күрсәтеп бирүендә. Нурихан Фәттах аны әле 1968 елда ук «чын сәнгать әсәре» дип атады. Атилла Расих исә «Гомәр аганың бу әсәре «Намус»тан көчлерәк» дип раслады. Әйе, безнең карашка да әлеге повесть һәм «Җидегән чишмә» романы сәнгатьчә эшләнеш ягыннан тагын да югарыга күтәрелү булды. Димәк, Г. Бәширов үзенең олы әдип, чын талант иясе икәнлеген бер генә тапкыр расламады. «Яшел бишек»тә мине укучы буларак

---

[1] *В. Г. Белинский.* 3 т.— 1948.— 36 б.

иң сокландырганы әдипнең татар гаиләсендәге мохитне сурәтләве булды. Биредә гаиләнең һәр әгъзасы үз урынында. Ата йорт-җирнең тулаем иминлеге, өйдәгеләренең матди хәле һәм гореф-гадәтләрнең гарантиясе булса, ана — шушы мохитнең эчке җылылыгын, әхлакый сафлыгын, үзара мөнәсәбәтләрнең самимилеген саклаучы. Балалар исә ата белән ана арасын тагын да якынайтучы, ныгытучы хезмәтен үти, ник дигәндә, уртак йөрәк җимешләре турында даими кайгыртып тору аларның яшәү рәвеше булып әверелгән.

Бәшир ага — чын татар ир-аты. Уйлап карасаң, бүгенге көндә күпчелек гаиләләрдәге бәхетсезлек, тиешле тәртип булмау — нәкъ менә ата кешенең үзенә төшә торган вазифаны башкара алмавында. Аларның күпчелеге акча тота алмый. Кулына килеп керсә, аракыга-фәләнгә сарыф итә. Шуның нәтиҗәсендә балалар тиешле тәрбия күрми, хатынының үзүзен карарга мөмкинлеге калмый. Бу исә аларның аралары бозылуына, һаман ерагая баруына, бер-берсен аңламауга китерә. Гомәр үскән гаиләдә исә мондый хәлнең булуы мөмкин түгел. Биредә ир белән хатын бер-берсен тулыландырып яши. Ата-ана үзләре дә даими эштә, балалар да кул арасына керә. Эшләп булдырылган әйберләрнең кадере арта, аның хәләллеген тою хисе кеше психологиясенең сыйфатын яхшырта. «Яхшы гаилә — тормышның нигезе» дигән фикер бу очракта сәнгатьчә көч белән раслана. Әсәрнең бүгенге көндәге актуальлеге шуның белән дә аңлатыла.

Сәнгатьлелеккә ирешүдә язучының иң төп коралы — тел. Г. Бәширов әсәрләрендәге тел тукымасының гүзәллеге турында бик күп сөйләргә мөмкин. Телне ул мөстәкыйль образ дәрәҗәсенә күтәреп куллана белә. Шушы хәл әдәби сүз остасының югары сәнгатьлелек дәрәҗәсен күрсәтеп тора.

Без Гомәр ага Бәшировны матурлык җырчысы дидек. «Җидегән чишмә» романында матурлыкның гәүдәләнеше булган табигатькә мөнәсәбәт образларны уңай яки тискәре төркемгә бүлүче төп бизмән булып хезмәт итә. Ул моны аңлы рәвештә эшләде. «Хәзерге авыл пейзажын матур әдәбиятта ничек сурәтләү хакында сүз чыккач,— дигән иде ул,— бер язучы:

— Хәзер инде элекке шикелле чишмәле, сандугачлы авыл турында сүз бармый, хәзерге авыл заманча булырга тиеш! — дигән иде.

Нигә әле хәзерге заман авыл кешесе сандугачлы, тургайлы, чишмәле табигатьтән ваз кичәргә тиеш икән? Минемчә, нәкъ киресенчә. Табигатьне тагын да баетырга омтылу кирәк». Иҗатның беренче чорында ук «Урман шаулый» дигән хикәя

язуы очраклылык булмаган, мөгаен. «Бибек нигә елый?», «Сарут» кебек хикәяләрендә исә хайваннар белән кеше арасындагы мөнәсәбәтне әдип, бик тә гыйбрәтле итеп, куе буяулар белән тасвирлады. «Җидегән чишмә» Г. Бәшировны, ниһаять, чын җырчы әдип итеп танытты. Әлеге әсәрдәге җыр тексты шулкадәр халыкчан, гади һәм шул ук вакытта олы хисләр белән сугарылган ки, Сара ханым Садыйковага аны шундый ук халыкчан моңлы көйгә салуы үзе бер ләззәтле шөгыль булгандыр. Яраткан җырчыбыз Зөһрә Сәхәбиева аны тыңлаучыларның йөрәгенә үк кертеп урнаштырды.

Гомәр ага гомеренең соңгы көннәренә кадәр иҗат каләмен читкә куймады. Туксанынчы елларда ул «Гыйбрәт» дигән роман язуын дәвам иттерде. Аның байтак кына сәхифәләре «Ватаным Татарстан» газетасының 1994 елның гыйнвар аендагы саннарында басылып та чыкты. Гомәр ага әлеге әсәрендә егерменче-утызынчы еллардагы бик тә аянычлы хәл-әхвәлләр турында бәян итә. Андагы вакыйгалар Арпаяз авылы белән бәйле. Хәер, ул еллардагы вазгыять барлык авыллар өчен дә типик иде. Хәзер бу әсәр китап булып укучыга барып ирешә.

Г. Бәширов татар сүз сәнгатендә үзенә бер дәверне тәшкил итүче, гаять күпкырлы иҗади шәхес иде. Аның бай әдәби мирасы күп дистә еллар буена халкыбызга игелекле хезмәт итте. Шунысы әһәмиятле: Г. Бәширов иҗаты идеология үзгәрешләренә карап кына үзенең кыйммәтен җуймый. Чөнки ул мәңгелек мәсьәләләр турында борчылып иҗат итте. Алар, билгеле булганча, вакытлы җилләргә генә буйсынмый. Ул калдырган романнар, повестьлар, хикәяләр һәм язма-мәкаләләр, халыкның рухи байлыгына әверелеп, безнең белән киләчәккә таба бара.

*2001 ел*

## ХАЛЫКТАН ҺӘМ ХАЛЫКНЫКЫ

Татар әдәбиятында Фатихлар байтак. Фатих Әмирхан, Фатих Кәрими, Фатих Сәйфи-Казанлы, Фатих Кәрим... Аларның һәрберсе үзенә бер Фатих. Бер-берсен кабатламый торган, әдәбиятта яңа сүз әйткән, халкыбызга олы хезмәт күрсәткән шәхесләр. (Сүз уңаенда Фатих исеменең «ачучы», «башлап җибәрүче», «яулап алучы», «җиңүче» дигән мәгънәләрне белдерүен дә әйтү урынлы булыр.) Шулар рәтендә үзеңнең дә Фатих булуыңны раслау, әлбәттә, җиңел эшләрдән түгел. Ләкин Хөснетдин улы Фатих моны эшләде һәм узган гасырның икенче яртысындагы татар әдәбиятында иң күренекле прозаикларның берсе булып танылды. Әгәр дә бүген әдәбиятыбызда Фатих